Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Ширәмәт авыл җирлеге составына керүче Оша пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2021 елның 16 ноябре

№ 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Ширәмәт авыл җирлегенең Оша пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Ширәмәт авыл җирлеге Оша пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 600 сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны Нагорная һәм Үзәк урамнарындагы урам коеларын урнаштыруга (төзелеш материаллары сатып алуга, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләүгә) юнәлдерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ширәмәт авыл җирлеге башлыгы В.И.Никишин